**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423646 Республика Татарстан, Менделеевский район, д.Псеево ул. Центральная, д.4

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423646 Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Песәй авылы, Үзәк урам,4 йорт

Тел. (факс): (85549) 3-71-22 e-mail: Psv.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

1 ноябрь 2025 ел № 5

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Песәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 14 ноябре 14.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында Яшьләр урамы, Яшьләр тыкрыгы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2025 елның 14 ноябре 15.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында Үзәк, Мичурин урамнары буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2025 елның 14 ноябре 16.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында Тукай, Чишмә, Дала урамнары, Дала тыкрыгы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Җыеннарның барлык этапларын уздыру урыны итеп Песәй авылы, Мәктәп тыкрыгы, 3 йорт адресы буенча урнашкан Песәй авыл мәдәният йортын билгеләргә.

Песәй авылында яшәүчеләр исемлеген җыен этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

- беренче этап: Яшьләр урамы, 1-28 йортлар, Яшьләр тыкрыгы, 3-5 йортлар;
- икенче этап: Мичурин урамы, 1-27 йортлар, Үзәк урам, 1-19 йортлар;

- өченче этап: Тукай урамы, 1-27 йортлар, Чишмә урамы, 1-13 йортлар, Дала урамы, 1-16 йортлар, Дала тыкрыгы, 1-9 йортлар.

5. Гражданнар җыенында түбәндәге сорауны расларга:

«2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясенә сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын азат итеп, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

«1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Мичурин, Чишмә, Тукай, Дала урамнары, Дала тыкрыгы буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш, асфальт валчыклары сатып алу, тигезләү) Песәй авылындагы юлларны кардан чистарту ) ;

2) каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Песәй авылында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү буенча хезмәт күрсәтүләр);

3) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (төзекләндерү элементларын буяу өчен буяулар сатып алу, Песәй авылында агачларын кисү);?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Песәй авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге башлыгы ______________ В.И.Мөхәммәтгалеев
(имза) (имзаны киңәйтү)